ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

09.01.2024 № 1

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе күрсәтә торган түләүле хезмәтләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 01 июнендәге 486 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Спорт мәктәбе» махсус исеме белән өстәмә белем бирү дәүләт учреждениеләренә спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган дәүләт учреждениеләре исемнәре үзгәртелүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Россия Федерациясе Спорт министрлыгы карамагындагы федераль бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә карый торган физик һәм юридик затлар өчен билгеләнгән дәүләт заданиесеннән тыш, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда, дәүләт биреме чикләрендә күрсәтелгән хезмәтләр (эшләр) өчен түләүне билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 елның 12 октябрендәге 933 номерлы боерыгы нигезендә, бюджет учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту, агымдагы чыгымнарны түләүне һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыруны тәэмин итү өчен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе күрсәтә торган түләүле хезмәтләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 01 июнендәге 486 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә (алга таба - Карар):

1.1. Карар исемендә, Карар тексты буенча һәм алга таба текст буенча аңа кушымталарда учреждениенең исемен «өстәмә белем бирү» сүзләре белән тулыландырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе».

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе күрсәтә торган

түләүле хезмәтләргә бәяләр прейскурантын 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Инеш» ябык йөзү бассейны тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.4. Карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 абзац белән тулыландырырга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Эверест» ябык футбол манежы күрсәтә торган түләүле хезмәтләр (эшләр) өчен бәяләр (тарифлар) прейскурантын 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarctan.ru/ веб-адрес буенча бастырырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://ysokaya-gora.tatarctan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның
09.01.2024 1нче номерлы карарына

Килештерелде
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

____________Д.Ф.Шәйдуллин

Раслыйм
«Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитеты» МКУнең «Яшьләр эшләре
һәм спорт бүлеге» МКУ бүлеге
башлыгы
_____________С.М.Чапурин

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә (эшләргә) бәяләр (тарифлар) прейскуранты**

| № т/б | Хезмәт күрсәтүнең (эшнең) исеме | Бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1 | Мини-футбол, волейбол, баскетбол буенча шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыгы бирү (бер дәрес озынлыгы - 1 сәгать) | 2000,00 |
| 2 | Көрәш һәм бокс рингы келәме бирү (бер дәрес дәвамы - 1 сәгать) | 2000,00 |
| 3 | Бадминтон, өстәл теннисы дәресләре өчен спорт мәйданчыгы бирү (бер дәрес дәвамы - 1 сәгать) | 500,00 |
| 4 | Физкультура-савыктыру төркемнәрендә шөгыльләнү өчен ирекле спорт мәйданчыгы (гимнастика, акробатика, шейпинг һәм башка спорт төрләре) бирү (бер дәрес дәвамы - 1 сәгать) | 700,00 |
| 5 | Тренажер залы: | |
| | Өлкән, бер тапкыр килү | 250,00 |
| | Студентлар, мәктәп укучылары бер тапкыр килү | 250,00 |
| | Өлкән, айлык абонемент | 1500,00 |
| | Пенсионерлар, көндезге уку формасы студентлары, мәктәп укучылары (айлык абонемент) | 750,00 |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның
09.01.2024 1нче номерлы карарына

Килештерелде
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

____________Д.Ф.Шәйдуллин

Раслыйм
«Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитеты» МКУнең «Яшьләр эшләре
һәм спорт бүлеге» МКУ бүлеге
башлыгы
_____________С.М.Чапурин

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Инеш» ябык йөзү бассейны тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр (тарифлар) прейскуранты**

| **1. Зур касә** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **1.1. Тренерсыз савыктыру йөзүе (дәвамлылыгы 1 сәг.)** | | | | |
| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Бер мәртәбә абонемент (сум) | Абонементлар (йөрү чоры 1 ай) | | |
| | | 4 килү | 8 килү | 12 килү |
| Өлкән (14 яшьтән һәм өлкәнрәк) | 300 | 1000 | 1900 | 2800 |
| 14 яшькә кадәрге йөзә белүче балалар | 250 | 900 | 1500 | 2000 |
| Пенсионерлар | 250 | 900 | 1500 | 2000 |
| Көндезге уку формасы студентлары | 250 | 900 | 1500 | 1500 |
| Гаилә (1 өлкән + 1 бала) | 500 | 1800 | 2900 | 4100 |
| Инвалидлар | айга бер мәртәбә бушлай | | | |
| **1.3. Бассейнның йөзү юлында спорт-савыктыру чаралары (1 сәг.)** | | | | |
| 8 кешедән артмаган бер юл өчен | 2500 | - | - | - |
| 4 юлга (бөтен касә) 32 кешедән артык түгел | 6000 | - | - | - |
| **2. Кече касә** | | | | |
| **2.1. Йөзәргә өйрәтү дәресләре (дәреснең дәвамы 1 сәг.)** | | | | |
| 6-14 яшьлек балалар (төркем) | | 1500 | 2800 | 3600 |
| Кече касә өчен 18 кешедән артык түгел | 2000 | 1500 | 2800 | 3600 |
| **3. Инвентарь прокатлау (дәвамлыгы1 час)** | | | | |
| Коткару жилеты, җиңсәләр, йөзү тактасы һәм б.ш. | 100 | | | |
| **4.Индивидуаль дәрес** | 1200 | | | |

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның
09.01.2024 1нче номерлы карарына

Согласовано
Руководитель исполнительного
комитета Высокогорского
муниципального района
Республики Татарстан

____________Д.Ф.Шайдуллин

Утверждаю
Начальник отдела МКУ «Отдел
по делам молодежи и спорту МКУ
«Исполнительный комитет
Высокогорского муниципального
района Республики Татарстан»
_____________С.М.Чапурин

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең «Эверест» ябык футбол манежы күрсәтә торган түләүле хезмәтләр (эшләр) өчен бәяләр (тарифлар) прейскуранты**

| № т/б | Хезмәт күрсәтүнең (эшнең) исеме | Бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1 | Мини-футбол буенча шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыгы бирү<br>(бер дәрес озынлыгы - 1 сәгать) | 2500,00 |